ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

16.11.2021 д. Канаш __ №9

Югары Ослан муниципаль районы Канаш  авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 1 нче декабрендә 10 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Нижнее Озеро авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә;

1.1.2021 нче елның 1 нче декабрендә 11 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы ТКанаш авыл җирлеге Нижнее Озеро авылы гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә;

1.2. 2021 нче елның 1 нче декабрендә 13 сәгать 00 минутта Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Нижнее Озеро авылы гражданнарының үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын билгеләргә.

2. Халык исемлеген бүлү территориаль билге буенча башкарыла.
1 этап: Нижнее Озеро авылы Мәктәп урамы халкы (1нче йорттан 23нче йортка кадәр);
2 этап: Нижнее Озеро авылы Яшьләр урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 33нче йортка кадәр);
3 этап: Нижнее Озеро авылы Боевая урамында яшәүчеләр (1нче йорттан 40нчы йортка кадәр).

3. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

«Нижнее Озеро авылындагы Боевая урамы буенча юлга вак таш салу»
«ӘЙЕ» «ЮК»

4. Халык җыеннарын үткәрергә:
1 этап: Нижнее Озеро авылы Мәктәп урамы буенча 10-нчы номерлы йорт янында;
2 этап: Нижнее Озеро авылы Яшьләр урамы буенча 12-нче номерлы йорт янында;
3 этап: Нижнее Озеро авылы Боевая ур., буенча 22-нче номерлы йорт янында

5. Халык җыенын Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетына оештырырга.

6. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков